УДК.821.512.145

*Хурматуллина Р.Ш., кандидат филологических наук, доцент, Набережночелнинский институт ФГАОУ ВПО «Казанский (Приволжский) федеральный университет».*
*Шамарова Г.Б., кандидат филологических наук, доцент, Набережночелнинский институт ФГАОУ ВПО «Казанский (Приволжский) федеральный университет».*

# НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВА ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ОБРАЗЛАР БИРЕЛЕШЕ

# ИЗОБРАЖЕНИЕ ОБРАЗОВ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ НАБИРЫ ГИМАТДИНОВОЙ

*Аннотация. Невероятная сила притягательности книг Набиры Гиматдиновой, их способность завоевывать читательскую любовь заставляет призадуматься литературных критиков и коллег по перу. Хотя вроде бы никаких секретов тут нет. Автору достаточно лишь понять психологию описываемого героя и суметь обернуть рутинный быт персонажа полупрозрачной вуалью «поэтического обмана». Но этот «обман» должен быть убедительным для читателя, он должен его взволновать и заставить сопереживать. Основной целью данной статьи является исследование способов изображения образов и создания этого «поэтического обмана» в произведениях Н.Гиматдиновой; раскрытие её индивидуальных языковых приемов и определение вклада писателя в развитие и обогащение татарского литературного языка.*

*Ключевые слова: татарская литература; изображение образа; язык писателя; Набира Гиматдинова.*

Төп сурәтләү предметы кеше булган әдәбиятта кеше образлары иң әһәмиятле рольне башкара. Аларның бирелеше катлаулы күренеш хасил итә. Ләкин әдәбият кеше образлары тудыру белән генә канәгатьләнә алмый. Әдәби әсәрдә кеше образлары белән янәшә хайваннар, үсемлекләр, кошлар, әйберләр, табигать стихиясе дә телгә килергә, эш-гамәлләр кылырга һ. б. сәләтле була. Алар әдәби әсәрдә үзәк урынны биләргә йә булмаса аерым бер күренешләрдә, ситуацияләрдә калкып чыгарга мөмкин. Табигать һәм әйбер образлары вазифалары ягыннан кешене алыштырып яки кеше образын тулыландырып

киләләр. Кайбер жанрларда, мәсәлән, әкиятләрдә, мәсәл һәм балладаларда, фәнни фантастикада мондый образлар булу табигый [2, 10 б].

Димәк, образ – әдәби иҗатның табигатен, формасын билгели торган төп төшенчә. Чынбарлыкны җанлы итеп күз алдына китерү өчен әдәби әсәрләрдә аерым күренешләр сурәтләнеп бирелә. Укучыга эмоциональ- эстетик тәэсир ясый торган чаралар барысы да образлылыкны алып килә. Ә бит күп очракта текст сүзнең туры мәгънәсен куллану белән, предмет һәм күренешләрне туры мәгънәсендә иң кирәкле, күзгә бәрелеп тора торган сыйфатларын тотып алып әйтү юлы белән ясала. Бу билгеле, язучыдан зур осталык таләп итә. Моның өчен аның тирә-як дөньяны, табигатьне, кешеләрне – барысын да тирән аңлый белүе кирәк. Икенче төрле әйткәндә, язучыда эчке тоемлау бик көчле булырга тиеш.

Гадәттә, аллегорик образларга мөрәҗәгать итәргә яратучы авторлар иҗатында әйберләрне, табигать күренешләрен күчерелмә мәгънәдә куллану күренеше еш очрый. Кайбер иҗатчылар күчмә мәгънәләрнең вариантлары күренеп торырлык итеп, символлар тудыралар.

Әдәбият белемендә мондый сурәтләрне билге, яки эмблема төшенчәсе белән атыйлар. Аларны берничә тотрыклы аллегорик – символик мәгънә белдерүче әдәби әсәр эчендә шуның берсе сайлап алына торган образ буларак бәяләү яшәп килә. Билге өчен иң мөһиме – мәгънә белдерү мөмкинлеге, аңа мәгънәви тотрыклылык, төгәллек хас. [1, 43 б].

Табигать образларының билге булып килүе фәлсәфи әсәрләрдә күзәтелә. Мәсәлән: карурман – тормыш билгесе, су кеше гомерен белдерә, көз – традицион картаюны, җир шары – тереклек. Тау – кеше аллегорик пары әдәбиятта еш очрый. Болыт аллегорик образы һавалы кешене белдереп килә. Табигать кешенең табигый берлеге, яшәеш фәлсәфәсен ачып җибәрә. Әйе, образ – әсәрне ачык, аңлаешлы һәм истә кала торган итүче иң зур чара.

Образлылык ягыннан язучы Нәбирә Гыйматдинова иҗаты татар әдәбиятында үзенчәлекле урын алып тора. Аның өчен һәр күренеш, кечкенә

деталь дә мөһим, мәгънәле. Язучы үз чараларын, үз образларын тудырган. Нәкъ шушы сыйфатлар индивидуаль стильнең нигезендә ята.

Н. Гыйматдинованың әсәрләре, әдәби тәнкыйтьнең гомум фикеренчә, үзенчәлекле язу стиленә, тасвирый осталыкка ия булу һәм уку өчен мавыктыргыч сюжетка корылулары өстенә җәмгыять өчен, кешелек өчен, милләт өчен мөһим мәсьәләләрне күтәрүе белән аеруча игътибарга лаек. Беренче әсәрләреннән үк кызыл җеп булып сузылып килгән, бүгенге көндә кешелек дөньясын иң борчый торган темаларның берсе – кеше шәхесе белән табигать арасындагы гармониянең бозылуы, адәм балаларының табигатьтән ераклашуы һәм шуның нәтиҗәсендә җәмгыятьтә явызлык артуы, кешеләр холкында бер-берсенең язмышына карата битарафлык көчәюе, әхлакый-рухи бөтенлекнең какшавы мәсьәләләрен үзәккә алып тасвирлау, шул идея-эстетик яссылыкта кызыклы, сәнгатьчә тулы канлы, тормышчан, кайвакыт гаять тә серле-гыйбрәтле кеше образларын тудыру язучы иҗатының төп фикер юнәлешен һәм үзенчәлекле әдәби казанышларын билгели.

Н.Гыйматдинова повестьларын берләштерә торган, алар өчен уртак булган бер сыйфат, элемент бар: ул – үзәк герой сурәтләнеше, аның характеры. Камилла яки Хаят, Акчәч яки Сара, Сәвилә яки Җәмилә, Мөнәвәрә яки Галия – әсәрдән-әсәргә күчүче бер тип геройлар. Башкаларга охшамаган, дөньяга үзенчә генә карый торган, изге-олы күңелле, чибәр һәм мәрхәмәтле, мәхәббәт хакына барысын да эшләргә әзер, әсәрләрдә сурәтләнгән тормышта бәхеткә ирешә алмаган бу хатын- кыз әсәрдәге башка геройларга замандаш түгел кебек тоела. Әйтерсең, Камилла – Шамилә һәм Шәңгәрәйләр («Китәм, димә») яшь булган вакыттагы кеше тибы, Хаят («Утарда») – кайчандыр бик ерак заманнарда гына яшәгән хатын-кыз кабатланышы, Сара («Ак торна каргышы») – хыял дөньясыннан төшкән «ак торна», Акчәч («Болан») — борынгы мифлардан күчкән болан-кыз...

Тәнкыйтьчеләр бу тип геройларны «җирдән аерылганнар», «табигать белән кеше арасында арадашчылар» дип тә атаган иде. Инде Нәбирә Гыйматдинованың бүгенге иҗат байлыгы ноктасыннан торып, аның үткән

заман хатын-кыз архетибын тудыруын, татар әдәбиятына үзгә бер хатын-кыз алып килүен күрсәтер чак җитте, -дип язган иде галимә Д.Ф.Заһидуллина, «архетип» төшенчәсенә түбәндәге аңлатманы биреп.

«Әдәбиятта кабатланып торучы, төрле чор язучылар иҗатында күренеп ала торган образлар була. Галимнәр фикеренчә, мондый образлар борынгы кешеләрнең психологик тәҗрибәсе нәтиҗәсе булган кеше моделен тергезәләр. Гадирәк әйтсәк, бик борынгы заманнарда ук аерым сыйфатлары калку күренеп торган кеше типлары билгеләнгән, бәяләнгән. Мондый мәгълүмат аңнан тыш (подсознание) тирәнлекләрдә буыннан-буынга тапшырып киленгән. Әдәби әсәрләрдә әлеге мәгълүмат, язучының таланты белән бизәлеп, яңадан мәйданга чыга. Милли әдәбиятлар да үз архетипларын бирә. Татар әдәбиятында иң билгеле архетип булып Акъәбиләр образы — аклык, сафлык, корбанчылык сыйфатын калку гәүдәләндергән өлкән буын хатын-кызы һәм «ил анасы» архетибы – Саҗидәләр (М. Галәу), Нәфисәләр (Г. Бәширов) кебек ил, милләт мәнфәгатьләре белән яшәгән хатын-кыз санала дисәк, ялгышмабыз» [3, 155 б].

Архетип табигатькә һәм кешегә зыян салмыйча**,** үз күңелен саф-чиста тотып яшәргә омтылуның киләчәк фаҗигаләрдән котылу юлы икәнлеген ассызыклый**.** Алай гына ла түгел, кешенең дөньяга килү максатын, яшәү мәгънәсен табу-күрсәтү баскычына күтәрелә. «Кеше дөньяга иҗат итәргә, матурлык тудырырга (Сара, Камилла), башкаларга ярдәм итәр, яшәү көче бирер өчен килә (Акчәч, Хаят). Шуны онытмасак иде»,- ди сыман автор.

Н.Гыйматдинова иҗатындагы архетип гуманистик, гомумкешелек идеясен белдерү мөмкинлегенә дә ия. Аның әсәрләрендә үткән заман хатын-кызлары ялгыз. Шушы ялгызлык, теләктәшләр яки аңлаучылар булмау – фаҗигагә китергән сәбәпләрнең берсе Кешеләрнең аңлашып, берләшеп, ярдәмләшеп яшәү зарурияте укучы тарафыннан нәтиҗә кебек ясала.

Әсәрләрдә әлеге хатын кыз белән каршылыкка кергән ир-ат төрле: Арыслан («Ак торна каргышы») яки Рөстәм («Утарда»), Сәйдәш («Китәм, димә») яки Рыскол («Болан») – характерлары, язмышлары барысын да үткән заман хатын-кызы белән очраштырып сыный. Ир-егетләр дә сынауны

һәрберсе үзенчә уза. Көрәшчегә әйләнгәннәре дә (Арыслан), юл чатында, сайлау алдында калганнары да (Сәйдәш, Рөстәм), сынган-сыгылганнары да бар (Рыскол). Җир йөзендәге борынгы кешеләргә хас асыл сыйфатларны исә автор нәкъ менә хатын- кызда тергезә һәм аны матурлык-изгелек сакчысы, яшәү көче бирүче итеп күтәрә.

Архетип хатын-кыз янында заман хатын-кызлары да күп. Алар арасында күңеле белән Камиллага якын Рәсимәләр дә («Китәм, димә»), капма-каршы бирелгән Сәрия яки Гөлчәчәкләр дә («Ак торна каргышы») бар. Бу геройлар, нигездә, әсәрдә сурәтләнгән заманга, җәмгыятькә бәя бирү өчен хезмәт итәләр.

Н.Гыйматдинова иҗатында әсәрдән-әсәргә күчеп килүче, ләкин төрле модификацияләрдә бирелә торган карчык образлары да татар әдәбияты өчен хас булмаган, үзенчәлекле дип бәяләнерлек. Акъәни яки Сузгын («Күке төкереге», «Болан») үз күңеленә, рухына якын күреп, ярдәмгә килгән, төп геройны саклап яшәгән Шарлотта яки Камәр карчык («Китәм, димә», «Утарда») – төрле кешеләр. Акъәни һәм Сузгын – мәҗүсиләр, табигать һәм кеше туганлыгына ышанып, шуны саклап яшәүчеләр булса, Шарлотта яки Камәр ышанулары ягыннан түгел, холык- фигыльләре белән ярдәмчел һәм изге. Ләкин беренче карашка төрле бу геройларны да бер сыйфат берләштерә: алар – архетипларның гомер кичкән, картайган кабатланышы. Тормышлары башка эздән китсә, язмыш юллары башкача сызылса, 30-40 елдан Камилла – Шарлоттага, Акчәч – Сузгынга, Хаят – Камәр карчыкка әверелгән булыр иде. Болар – бер чылбыр буыннары, ләкин автор тудырган дөньяда яшь героинялар язмышына мәхәббәт керә, алар үзләре өчен билгеләнгән юлдан читкә атларга җөрьәт итәләр. Шулай итеп дәвамчыларның көчле характерлы, көрәшче, үзсүзле, максатчан икәнлеге ачыклана.

Нәбирә ханымның Шәңкәлесе («Китәм, димә»), Давыл апасы («Синдә минем хакым бар»), Изге Коръәннең бер сүрәсе язылган китап битен сандык хәзинәсе итеп саклаган Солтан карты («Беләсеңме, сагындым…»), иң каргалган нигезләрне догадан мәхрүм итмәгән Мөслимә әби («Эзләмәгез Җирдән…») кебек саваплы әбиләре татар кавеменә затсызлык кармавычлары үтеп керә

башлаганчы сыйфатыбыз ниндирәк булганны чамаларга ярдәм итә. Китап укучы халык аның әсәрләренә шул югалган затлылыкны эзләп тә тартыла булыр. Һәм ул, үзе дә абайламастан, борчыла, чистарыну чарасын эзли башлый.

Повестьларда төп героиня белән каршылыкка керүче өлкән хатын-кызлар (Сузгын, Убыр һ. б.) дөньяны – тәмуг, кешене – аждаһа итеп күрәләр. Ләкин шушы карашка үзәк герой фикере каршы куела, аның кешене һәм дөньяны матур, саф итеп күрүе, үзгәртә, камилләштерә алырлык көчле сурәтләнеше автор фәлсәфәсенең ниндилеген ассызыклый.

Автор яшәешне капма-каршы көчләр бүленеше итеп күзаллый. Матурлык һәм Яхшылык – табигатьтә, кеше күңелендә, канында. Явызлыкка җәза бирерлек көч тә, ямьсезлек һәм усаллык та табигатьтә һәм Кеше җанында яши. Усаллык, Явызлык ягы баса башладымы, афәт, фаҗига, югалтулар килә. Акчәчләр һәм Саралар, үз гомерләрен корбан итү хакына булса да, шуңа каршы чыгалар. Ләкин автор Ак һәм Караны тигезләнгән үлчәү тәлинкәләре кебек карамый. Автор караны юк итү, бетерү хакында уйлана. Аның үткән заман хатын-кызлары Явызлыкка җәза бирерлек, аны җир йөзеннән юк итәрлек көчкә ия түгел. Шулай булса, әсәр ышандырмас та иде. Алар – җәмгыятьнең ялгыш юлдан китүе хакында хәбәр итүчеләр, өн салучылар, кисәтүчеләр. Мәсәлән, «Тәкъдир» повестендә авторның фәлсәфи фикерләре кызыклы: «Безнең яшәү – ак белән караның чиратлашып еллар упкынына коелуы» ди ул. Н.Гыйматдинова үз әсәрләрендә китап укучыга гомернең кадерен белеп, игелек кылып, яхшы уй уйлап, мәгънәле итеп Яшәү кирәклеге хакында сөйли.

Вакыйгалар ярдәмендә автор кешенең, беренче чиратта, үз-үзен харап итүен, үзенә явызлык кылуын да раслый. Мондый кисәтү вазифасы тискәре образларга йөкләтелә**.**

Аек акылындагы яисә акыллы булып күренергә тырышучы кеше җөрьәт итеп әйтә алмаган кыю сүзне «сәер»ләрдән әйттерү хәйләсе Нәбирә Гыйматдинова табышы гына түгел, әлбәттә. Аурупа әдәбияты хәзер мондый «тел яшерү»гә мохтаҗ түгел инде. Әмма безнең канга сеңгән саклык исән әле. Язучы әсәрләрендәге «сәер»ләрнең – Дәрвишнең, Шагыйрьнең, Дивананың,

Сашканың, Пылаучы картның өстәмә вазыйфалары да бар. Татар фаҗигасе хакында ачыктан-ачык чаң кагуларны ишетергә теләмәгән бер заманда «сәер»ләрнең вәхиләренә кем колак салыр икән соң?! Әмма әдәби әсәрнең көче дә шунда.

Нәкъ менә үз идеалын – укучы идеалын, чөнки соңгы повестьларда язучы идеалы – үткән заман хатын-кызы архетибы юк. Аның белән бергә сагышлы-хыялый, тылсымлы – ак дөнья да югала. Әйтерсең лә бу әсәрләрдә Акчәч һәм Саралар фани дөньяны кичкәннән, Хаят һәм Камиллалар гаип булганнан сон, аларсыз гына ага башлаган тормыш сурәтләнә, һәм бу тормыш Н. Гыйматдинова иҗатындагы асыл матурлык – шул Хаятләр һәм Акчәчләр җаны, рухи байлыгы икәнен тагын бер кат искәртеп тора. Укучы буларак, соңгы повестьлар белән танышканда да әлеге сәеррәк һәм самими затларны эзлисең, аларсыз сурәтләнгән яшәеш исә гади-гадәти, буш һәм җансыз булып тоела.

Әсәрләрдә авторның фәлсәфи фикере дә үзгәреш кичергән. Соңгы повестьларда Кешенең кешелеклелеккә кайтуы, явызлыктан баш тартып, яхшылыкка омтылу мөмкинлеген язучы тулысы белән аның үзенә бәйли. Елан кабыгын салган кебек, шәхес тә йөзен, битлеген үзгәртә ала, хаталарын аңлап, үкенеп, башкача яши башларга аңа беркайчан ла соң түгел, ди сыман автор.

**Кулланылган әдәбият**

1. Акмал Н. Язмыш тугайлары боргаланып беткән.../Н. Акмал //Мәйдан. –2002. – №2. - 43 б.

2. Заһидуллина Д.Ф. Образлар системасын анализлау //Әдәби әсәргә анализ ясау, Заһидуллина Д.Ф., Ибраһимов М.И., Әминова В.Р. – Казан. 2005, 5–7 б.

3. Заһидуллина Д. Яңа дулкында //Казан утлары. – 2003. – № 1. – 152–159б.

---

*Hurmatullina R. Sh., Shamarova G. B. ,candidates of Philological Sciences, associate professor, Naberezhnye Chelny institute of Kazan (Volga region) Federal University*

# DESCRIPTION OF CHARACTERS IN N. GIMATDINOVA PIECES OF WORK

*Abstract. Attractiveness of Nabira Gimatdinova's books, their ability to gain the reader's love makes lit-crits think. It is just enough for the author to understand the psychology of the described character and wrap the routine life into poetic deception.*

*The main aim of this article is to investigate the methods of characters description and creation of this "poetic deception" in Nabira Gimatdinova's pieces of work; revel her individual linguistic patterns and define the author's contribution into the development and enrichment of the Tatar literature language.*

*Keywords: Tatar literature, character description, the author's language, Nabira Gimatdinova.*